# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 3 (703) 12 февраль 2020 ел (1441, Җөмәдел-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

*2020 ел - ТАССР төзелүгә 100 ел, Татарстанда Туган тел елы*

## Милләт вә дин файдасына



Күге астында яшәгән, һаваларын иснәп, суларын эчкән вә икмәкләрен ашаган ватаныгызны сөегез, моның исемен бөек итәр өчен тырышыгыз! Ватан адәмнәрнең хөрмәте вә һәркем алдында изге итәчәк бер мактаныч булыр. Шуның өчен Ватан тугрысында малыгызны кызганмагыз, көчләрегезне аямагыз. Ватан хакында болай фидакяр булмаган кеше анда яшәргә лаек түгелдер. Ата вә анагызны, якын кардәшләрегезне ничек сөйсәгез - милләтегезне шулай сөегез, милләтегез өчен хезмәт итүне җаныгызга зур табыш дип санагыз. «Милләт» вә «тәрәккыят», ягъни «алга китү» сүзләрен мәсхәрә итүчеләрнең сүзләрен ишетмәгез, алар исә — хисләрдән мәхрүм калган мескеннәр вә бичаралардыр. Бәлки аларның үзләрен кызганыгыз вә мондый дәрәҗәдә ким калулары өчен хәлләренә мәрхәмәт итегез! Милләт вә Ватан өчен хезмәт итү насыйп булса — аның бәрабәренә рәхмәт вә бүләк көтмәгез. Бүләк көтү шулай торсын; фараз итик, ягъни күз алдына китерик: милләт сезгә җәфа итсен, сез һич үпкәләмәгез, өстегезгә бурыч булган хезмәтләрдән һаман кире тормагыз. «Шәһәрләр вә кавемнәр һәрникадәр миңа җәфа итсәләр дә, минем күземдә генә хөрмәтлеләрдер» дигән гарәп шигырен укыгыз вә моның белән хәтерегезне юатыгыз! Дин, гыйлем тарату, мәктәпләр вә яхшы эшләр өчен, вә һәрни рәвешчә булса да халыкка ярдәм бирү өчен тырышлык сарыф итү —иң гүзәл гайрәттер, моның җәзасы да - гүзәл җәза булачактыр. Шуның өчен изге вә диндарлык эшләренә, милләт вә дин файдаларына ярдәм бирүне зур табыш санагыз, күңелегез белән сөя-сөя ярдәм бирегез, милләтегезгә гыйлем вә мәгърифәт таратыгыз, араларына дуслык вә мәхәббәт орлыклары чәчегез, дошманлык вә гөнаһ эшләргә ярдәм итешүдән саклаunion. Хосусан милләт зарарына бер хәреф тә сөйләмәгез вә бер нокта да язмагыз!

**(Риза Фәхреддин. “Әхлак гыйлеме”ннән)**

## Чаллы яңалыклары




Чаллы шәһәренең “Утыз Имәни” мәчетендә 7-13 яшьлек балалар өчен “Ислам һәм минем тирәдәге дөнья” дип аталган конференция узачак. Катнашучылар тәкъдим ителгән темалар арасыннан берне сайлап алып, аны Коръән һәм хәдисләр ярдәмендә аңлатырга тиеш була. Балалар үз эшләрен ата-аналары белән берлектә стенгазета, лепбук, брошюра форматында эшли алалар. Эшләрне 10 февральгә чаклы Әхмәдуллина Нәзирә Нәсим кызы почтасына (ahmadullina1983@mail.ru ) юлларга яки шәхсән тапшырырга кирәк. Белешмәләр өчен телефон: 89600678449. 16 февраль көнне иртәнге сәгать 9да “Утыз Имәни” мәчетендә аларны яклау булачак. Балалар 5 минут вакыт эчендә үз эшләре турында сөйләп бирергә тиеш була.

***

2 нче февральдән “Ак мәчет”нең якшәмбе курсларында яңа төркемнәр тупланды. Тәүге тапкыр укырга дип килгән шәһәрдәшләребезне имам-хатыйб Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев сәламләде һәм үзенең үгет-нәсыйхәтләрен житкерде.

***

Чаллының “Нур-Ихлас” мәчетендә “Ислам. Беренче адымнар” дип аталган, ислам дине нигезләрен өйрәтүгә багышланган дәресләр башланды. Әлеге проект Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан 2018 ел башында булдырылды һәм күпләгән кешеләр өчен нибары 5 дәрес эчендә дин нигезләрен өйрәнүгә яхшы мөмкинлек булды. Чаллы шәһәрендә әлеге проект буенча чаралар тәүге тапкыр 2019 елның беренче яртысында үткәрелде. Бу елны әлеге курсларга 30 га якын кеше йөрергә теләк белдерде. “Ислам. Беренче адымнар” проекты буенча дәресләр 5 атна дәвамында һәр шимбә “Нур-Ихлас” мәчетендә сәгать 9 да уздырыла. Дәресләрне шәһәребез мәчетләре имамнары алып бара.

## ТР МДН хәбәр итә



Җөмәдел-ахир аеның 12 нче көнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Теләче районында эшлекле сәфәрдә булды. Анда Теләче районы җитәкчесе Нәҗип Хажипов, нәзарәтнең Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов, Теләче районы имам-мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Фәләхиев та катнашты. Район мәдәният йортында нәзарәтнең Аксакаллар шурасының еллык утырышы булды. Нәзарәтнең аксакаллары, еллык җыелышы узганнан соң, Шәдке авылына сәфәр кылды. Биредә алар авыл зиратына кереп, күптән түгел автоһәлакәттә вафат булган Фәрит хәзрәт Шәйхиевның каберен зиярәт кылды. Исегезгә төшерәбез: Фәрит хәзрәт Шәйхиев 20 нче гыйнвар көнне арабыздан китте. Ул 15 ел дәвамында Шәдке авылында имам булып хезмәт итте.

***

Буа мәдрәсәсендә кичке бүлек шәкертләре өчен “Җирле әдәбиятта дини мотивлар” темасына мәгълүмати-агарту чарасы үткәрелде. Анда КФУның Филология һәм мәдәниятара бәйләнешлар институтының татар әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы, профессор Сәйфуллина Флера Сәгыйть кызы чакырылган иде. Мәдрәсә мөдире Илмир хәзрәт Хәсәнов үзенең сәламнәрен һәм рәхмәтләрен җиткерде.

***




Җөмәдел-ахир аеның 7 нче көнендә бөтен дөнья Халыкара хиҗаб көнен билгеләп үтте. Әлеге дата уңаеннан мәчетләрдә һәм Татарстан мөхтәсибәтләрендә гүзәл затлар өчен махсус чаралар узды. Түбән Каманың «Җәмигъ» мәчетендә мөслимәләр өчен остазлар белән очрашу оештырылды. Алабуга мөслимәләре өчен берничә мөһим кичә үткәрелде. Бөгелмәдә «Ирхам» мәчетендә «HIJAB Day» исеме астында очрашу 50 дән артык хатын-кызны җыйды. Чаллы мөхтәсибәтендә Хиҗаб көнен “Милли кием бик килешә үзеңә!” темасы буенча түгәрәк өстәл артында билгеләп үттеләр. Казанның «Тантана» залында «Зәкят» Хәйрия фонды WORLD HIJAB DAY кичәсен уздырды. Мондый чаралар әле дә дәвам итә.

***

Җөмәдел-ахир аеның 11нче көнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Әлмәт районында булды. Монда ул шәһәр һәм район башлыгы Тимур Нагуманов белән күреште. Җитәкчеләр районадагы дини вәзгыятьне яхшырту өлкәсендә мөхтәсибәт һәм җирле хакимиятнең хезмәттәшлеген үстерү хакында фикер алыштылар. Эш сәфәре барышында Камил хәзрәт шулай ук Диния нәзарәтенең «Нур» татар мәктәбе эшчәнлеге белән танышты. Татарстан мөфтиенә мәктәп буенча экскурсияне Әлмәт имам-мөхтәсибе Фәһим хәзрәт Әхмәтҗанов оештырды. Хәзерге вакытта мәктәптә 36 бала белем ала. Биредә дәресләр рус һәм татар телләрендә алып барыла. Малайлар һәм кызлар аерым сыйныфларда белем ала. Белем бирү учреждениесенең оештыручысы – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм Әлмәт мөхтәсибәте.

# Йөрәгең сәламәт булсын

***“Ул көнне кешегә байлыгы да, балалары да файда итмәс. Мәгәр Аллаһка сәламәт йөрәк белән килүчегә генә файда булыр”. («Шүгара», 88-89)***

***“Тәндә бер әгъза бар. Әгәр ул сәламәт булса, бөтен тән сәламәт була. Әгәр ул бозылса, бөтен тән бозыла. Ул әгъза – йөрәктер”. (Хәдис)***

Кадерле кардәшем! Аллаһның дошманы Иблис һәрвакыт, нинди генә юл белән булса да, сине Раббыңа гыйбадәт кылудан, Раббыңны зикер итүдән, җәннәт юлы исламнан ерагайтырга тырыша. Ширек, көферлек һәм башка төр фәхешлекләргә чакырып, мәңгелек хәсрәтле итмәкче була. Әгәр шайтан сине изге гамәлләрдән ерагайта алмаса, ул синең изгелекләреңне рия белән бетерергә тырыша. Рия – ул бик тә куркыныч авыру, чөнки беренчедән, кеше аның белән авыруын сизмәскә дә мөмкин. Икенчедән, ул кешенең кылган гамәлләрен юкка чыгара.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Сезнең өчен дәҗҗалдан да ныграк нәрсәдән курыкканымны әйтимме?” Сәхәбәләр: “Әйт, Аллаһның илчесе”, - диделәр. Пәйгамбәребез с.г.в: “Яшерен ширек. Кеше намазга баса һәм аңа кешеләр карап торганын белеп, намазын бизәп укый”, - дип җавап бирә. “Сезнең өчен иң курыкканым – кече ширек”. Сәхәбәләр: “Нәрсә соң ул кече ширек?” – дип сорадылар. Ул: “Рия”, - дип җавап бирде.

Хакыйкый мөселман һәрвакыт гамәлләрен Аллаһ ризалыгы өчен кыла һәм беркайчан да кеше күрсен дип эшләми. Чөнки гамәлләрен рия белән кылучыга әҗер юк, аның эшләре тузан бөртегенә дә тормый. Кыямәт көнендә кешеләр хисап өчен җыелгач, ул үкенечле хурлыкта калачак.

Мөселманның максаты Аллаһның ризалыгына ирешү булса, риячының уенда ничек тә булса кешеләр каршында үзенең изгелекләре белән масаю. Кемдер үзенең гыйлеме, кемдер көче, байлыгы, кемдер кылган изгелекләре белән масая. Ләкин боларның барысы да Аллаһның нигъмәтләре. Һәм ул нигъмәтләрне Аллаһ кемгә теләсә бирә, кемнән теләсә кире ала. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) сәхәбәләре кылган эшләре белән масаю түгел, без кимчелекләребезне яшергән кебек, үзләренең изгелекләрен яшергәннәр. Кешеләр изгелеген белеп савабы кимүдән курыкканнар.

Шуны да онытма, кешеләрнең мактауларына ашкынып, шелтә-ризасызлыкларыннан курку да рияга илтә. “Бу эшне эшләсәм кешеләр нәрсә әйтерләр, миннән разый булырлар микән?” – кебек уйлар йөрәкне борчый башлый. Бел, кардәшем: Аллаһка гөнаһ булган эштә беркемгә дә итагать юк. Әгәр бездән Аллаһ риза булмаса, кешеләрнең мактаулары безгә бер файда да бирми. Әгәр бездән Аллаһ риза булса, кешеләрнең шелтәләре, ачулары бер зарар да китерә алмый.

Пәйгамбәребез с.г.в. әйтте: “Кем Аллаһның ризалыгына ашкынып, үз өстенә кешеләрнең ачуын алса, Аллаһ аны кешеләрнең зарарыннан саклар. Кем кешеләрнең ризалыгына ашкынып, үз өстенә Аллаһның ачуын алса, Аллаһ аны кешеләргә калдырыр.”

Рия сәбәпле, кешенең гамәлләре юкка чыга, чөнки ул Аллаһка тиңдәш кыла. Аллаһ фәкать Үзенең ризалыгы өчен генә кылынган эшләрне кабул итә. Пәйгамбәребез с.г.в әйтте: “Аллаһ Тәгалә әйтте: «Мин үземә тиңдәш кылуга мохтаҗ түгелмен. Әгәр кем дә булса гамәлен Минем өчен генә кылмаса, Мин аннан һәм Аның ширкеннән баш тартам”. (Мөслим)

Риячыларның Кыямәттә булачак хурлыклары турында пәйгамбәребез с.г.в. әйтте: “Кыямәт көнендә беренче хөкем ителүче – дин өчен шәһид киткән бер кеше булыр. Аны алып килерләр һәм Аллаһ аңа биргән нигъмәтләрен әйтер. Кеше аларны таныр һәм Аллаһ аннан: “Шөкер итеп нәрсә кылдың?” - дип сорар. Ул: “Мин шәһид киткәнче Синең юлыңда көрәштем”, - дип җавап бирер. Аллаһ аңа: “Син алдыйсың. Син кешеләр сине “батыр” дип әйтсеннәр өчен генә көрәштең”, - дип әйтер. Соңыннан аңа карата әмер бирелер һәм аны йөзе белән җирдән сөйрәп утка алып китерләр.

Икенче булып Коръән укып, гыйлем алган һәм гыйлемен башкаларга тараткан бер кешене алып килерләр. Аллаһ аңа дөньялыкта биргән нигъмәтләрен исенә төшерер, ул аларны таныр һәм Аллаһ аннан: “Аларга шөкер итеп нәрсә кылдың?”- дип сорар. Кеше: “Гыйлем җыеп, аны башкаларга өйрәттем һәм синең ризалыгың өчен Коръән укыдым”, - дияр. Аллаһ аңа: “Син алдыйсың, син бит гыйлемне синә “галим” дип әйтсеннәр өчен җыйдың”, - дип әйтер. Соңыннан ул кешене йөзтүбән утка ташланырга әмер бирелер.

Өченче булып гомере буе байлыгыннан мохтаҗларга өлеш чыгарган бер бай кешене китерерләр. Аңа да Аллаһ Үзенең нигъмәтләрен танытыр. Ул таныр. Аллаһ аннан: “Шул нигъмәтләремә рәхмәт йөзеннән нәрсә эшләдең?” – дип сорар. Ул кеше: “Мин Синең ризалыгың өчен мөмкин булган бөтен урыннарга малымны сарыф иттем”, - дип җавап кайтарыр. Аллаһ аңа: “Син алдыйсың, син бит сине “юмарт” дип әйтсеннәр өчен тырыштың». Соңыннан бу кешене дә җәһәннәмгә йөзтүбән атарга кушылыр.

Рия кылу, гамәлләрне кеше күрсен дип эшләү – ул монафыйклар сыйфаты. Монафыйклар Аллаһка гыйбадәт кылалар, ләкин йөрәкләрендә иман юк. Шул сәбәптән алар гамәлләрен рия белән, кеше күрсен өчен кылалар. Аллаһ алар турында нәрсә ди: “Дөреслектә, монафыйклар Аллаһны алдамакчы булалар. Ләкин Аллаһ аларның үзләрен алдый. Ул монафыйклар намазга ялкаулык белән, кешеләр күрсен өчен басалар. Аллаһны бик аз зикер итәләр”. («Ниса», 142)

Аллаһ гамәлләрен тыштан гына кылучы монафыйкларга газапның иң катысын вәгъдә итте: “Дөреслектә монафыйклар утның иң астында”.

Рия кешенең әҗерле эшләрен гөнаһка әйләндерә. Мисал белән, намаз укучыга Аллаһ дөньяда да, ахирәттә дә бик зур дәрәҗәләр вәгъдә итә. Ләкин берәү намазын рия белән кылса, аңа Аллаһның газабы. Аллаһ Тәгалә Коръәндә: “Намаз укучыларга хәсрәт”, - дип әйтә. Һәм нинди намаз укучыларга: “Кемнәр намазларына җиңел карыйлар” Ягъни, намазларын өмет һәм курку белән укымыйлар. Вакытыннан кичектерәләр. “Кемнәр рия кылалар”. Ягъни, әгәр намазларын укысалар, кешеләр күрсен өчен укыйлар. Башка изгелекләрен дә кешеләр күрсен дип кылалар. Мондый рәвештә намаз укучыларны җәннәт чишмәләре түгел, бәлки җәһәннәмдәге үлек сулары көтә. Аллаһ сакласын.

Әгәр кеше ихлас икән, шайтан ул кешенең күңеленә шик салырга тырыша һәм: ”Синдә рия! Син риячы! Синең гамәлләрең барыбер кабул булмый”,- дип аны изге эшләрдән ерагайтмакчы була. Калебенә шик-шөбһә сала. Шуңа күрә мөселман һәрвакыт сак, уяу һәм зирәк булырга тиеш.

Риячылар дөньяда яшәгәндә кешеләр каршында зур дәрәҗәләргә ашкынган булсалар да, кыямәттә алар хурлыкта калалар. Мәңгелек җәннәт бакчаларына керү урынына, алар мәңгелек утка керәләр.

Йә Раббым Аллаһ! Безләрнең йөрәкләребезне риядан һәм башка төр шайтан авыруларыннан сакласаң иде.

**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,**
**Казанның Идел буе һәм Вахитов районнары имам-мөхтәсибе.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

* Рәнҗетелгән кешенең догасыннан куркыгыз

* Кем Аллаһка тәвәккәл кылса, аның хаҗәтләрен үтәргә Аллаһ җитәдер

* Кемдер үзен рәнҗеткән өчен рәнҗетүчене каргап, гел дога кылса, Кыямәт көнендә рәнҗетүченең рәнҗетелгән кеше алдында өстенлеге булыр

* Сезнең хәерлеләрегез – кешеләргә күбрәк файда китерүчеләрегез

* Ачуланма! Ачулану сыйфатыннан азат булган кеше генә җәннәткә керә алыр

* Адәм баласы һәр нәрсәне – яхшысын да, начарын да үз гамәле белән китерә

* Тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк

* Мәзлүм кешеләрнең догаларыннан куркыгыз, алар белән Аллаһы Тәгалә арасында пәрдә юктыр.

## СОРАУ-ҖАВАП

# Бәддогадан сакланыйк

**Үземне борчыган бер сорау белән мөрәҗәгать итәм сезгә. Безнең мәктәпкәчә яшендәге ике улыбыз бар. Бик шук булганга, алар һәркөн диярлек нинди дә булса “ширлек” эшли. Тәрбия йөзеннән шелтәлим, аңлатырга тырышам, ләкин каенанам бу хәлне үзенчә “хәл итәргә” тырыша: балаларны “каһәр суккыры” һәм башка шундыйрак сүзләр әйтеп сүгә. Еш кабатлангач, балаларыма чыннан да берәр зәхмәт ирешмәс микән дип куркам. Бу хакта борчылуым дөресме?**

Бик кызганыч, әмма сорауда тасвирланган хәл шактый күп гаиләләрдә күзәтелә: ачу чыккан вакытта олылар балаларга гына түгел, бер-берсенә дә “бәддога” сүзләре җиткерә: начар теләк теләп, якыннарын тирги, каһәрли... Кызган чакта әрләүче бу сүзләрнең начар теләк булуын абайлап та бетермәскә мөмкин, ләкин “каһәр суккыры” яки “шайтан алгыры” кебек сүзтезмәләр – асылда начар теләк, дин телендә әйтсәк, “бәддога” була.

Нәрсә соң ул “бәддога”? Галимнәр аңлатканча, бәддога (яки ләгънәт) ул кемне дә булса Аллаһның рәхмәтеннән өздерү теләге, ягъни кешене Аллаһның ярдәменнән, яклавыннан мәхрүм итеп, аның авыр хәлгә төшүен теләү. Шундый теләк белдерү өчен ачуланучы күңелендә ачуланган кешегә карата бик зур нәфрәт булырга тиештер...

Шулай итеп, бәддога ул – башкаларга начарлык теләү. Тормыш күрсәткәнчә, начар теләк кешенең теленнән ачуы чыккан вакытта ычкынып китә. Нәкъ шуңа күрә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм, мөселманнарны кисәтеп, болай дигән: “Ачуланма! Ачулану сыйфатыннан азат булган кеше генә җәннәткә керә алыр...” Икенче бер хәдистә исә пәйгамбәребез (с.г.в.с.) безне: “Башкаларны беләге белән җиңгән кеше түгел, ә ачу чыккан вакытта үзен тыя алган кеше көчледер”, – дип кисәтте. Ә тыелырга бик тә кирәк, чөнки ләгънәт кылган вакыты фәрештәләрнең “әмин” дигән чагына туры килсә, теләк кабул ителер һәм “шайтан алгыры” дип орышылган баланы шайтан чыннан да үзе артыннан ияртеп, начар юлга кертеп җибәрер. Шуңа күрә гаиләдә килеп чыккан низагны хәлләрдә ләгънәт кылу сүзләрен әйтүдән бик нык сакланырга кирәк.

Ислам динендә гаилә әһелләрен генә түгел, гомумән, башка, чит кешеләрне ләгънәт кылу да тыела. Хәдисләрнең берсендә бу хакта шундый мәгълүмат бар: “Адәм баласы кемнедер ләгънәт кылса, аның бәддогасы күккә күтәрелер һәм шунда күк капкалары ябылыр, бәддогаены үткәрмәсләр. Шуннан соң бәддога кире жиргә төшеп китәр, әмма жир капкалары да аның өчен ябылыр. Төрле тарафларга бәргәләнеп үзенә урын тапмаганнан соң, бәддога ләгънәт кылынган кеше янына килер һәм ул бу догага лаеклы булса, аны зарарлар. Лаеклы булмаса, бәддога әйтүчегә әйләнеп кайтып, аны зарарлар”.

Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.с.) хәтта үзенең дошманнарын да ләгънәт кылмаган, “мин ләгънәт өчен түгел, ә рәхмәт өчен җибәрелдем”, – дип әйтә торган булган. Без, мөселманнар, пәйгамбәребез (с.г.в.с.) үрнәгендә башкаларга Аллаһның рәхмәте ирешүен теләргә тиеш. Хәтта шукланган балаларыбызны да: “И-и, рәхмәт төшкере!” – дип “ачуланырга” кирәк. Шулай итсәк, Аллаһның рәхмәте аларга чыннан да ирешер һәм киләчәктә балаларыбыз тәүфыйклы, бәхетле булыр.

**Җавапны Кукмара мәдрәсәсе мөдире Ришат хәзрәт Курамшин әзерләде.**

# Кыямәт көненең галәмәтләре

*(Дәвамы. Башы газетаның алдагы саннарында)*

Әле булмаган (киләчәктә булырга тиешле) кече галәмәтләр.

Кәгъбәнең җимерелүе.

Изге урын булуга карамастан, Кыямәт көне алдыннан Кәгъбә җимерелер. Җирдә гыйбадәт кылучылар бик әзәйгәнгә күрә, һәм хаҗ кылучылар булмау аркасында, Аллаһы Тәгалә моңа юл куя. Имам Мөслимнең хәдисләр җыентыгында шундый хәдис китерелә: Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: "Кәгъбәне Зәссүвәйкатәйни исемле кеше җимерер (аның исеме "кыска балтырлы" дип тәрҗемә ителә). Ул Кәгъбәне берәр таш итеп сүтәр. Шул вакытта җир йөзендә гыйбадәт кылучылар инде булмас". Габдулла ибне Әмер исемле сәхәбә риваять итүе буенча, Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: "Кәгъбәне кыска аяклы эфиоп сүтәчәк. Башта ул аның япкычын тартып төшереп диварларын ачачак, аннары көрәк һәм кәйлә белән вата башлаячак. Ул минем күз алдымда сыман: пеләш, кәкре аяклы..."

Ибне Габбастан тапшырылган хәдистә дә мондыйрак мәгълүмат бар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: "Үзем күргән шикелле: кара тәнле, кәкре аяклы ир кеше Кәгъбәне таш-таш итеп сүтә..."

Кәгъбәнең җимерелү факты Корьәндәге "Мәккә - кагылгысыз, имин шәһәр" дигән аятькә каршы килми, чөнки ул Кыямәт көне алдыннан Аллаһка гыйбадәт кылучы мөселманнар һәм хаҗ кылырга килүчеләр инде калмау сәбәпле җимерелер.

**("Ислам дине нигезләре"ннән.**
**Дәвамы бар)**

## ӘДӘБИ СҮЗ

**Мөҗәһит Әхмәтҗанов**

### «Әй бөгелә, әй сыгыла...»

*Әй бөгелә, әй сыгыла,*
*Сәлам бирә бер бәндә.*
*Безгә ят бу кылanулар*
*Хәтта патша күргәндә.*

*Тезләнеп кул үбүләр дә*
*Модада әле һаман.*
*Мөселманнар бу гадәтне*
*Кемнәрдән күреп алган?*

*Бөгелү – сәҗдәгә китү*
*Тиеш бары Аллага.*
*Сәламләшүнең серләрен*
*Белсен иде бала да!..*

**«Ислам нурына» — 25 ел**

# «Яхшылыкны яктыртырга кирәк»

*Интернет, гаджетлар, компьютер заманында яшәсәк тә, басма матбугатның, язма сүзнең җуелмас үз урыны, үз әһәмияте бар. Шул хакта Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе* **Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН** *белән сөйләшәбез.*



**- Халкыбызның язма сүз тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Әлфәс хәзрәт, сезнеңчә, фикернең "ташка басылып"калу хикмәте нидә?**

- Имам буларак, без дә, вәгазьләр әзерләгәндә, үзебезнең фикерләрне язып куябыз: башта вәгазьнең темасын карыйбыз, аннан, бу хакта Аллаһы Тәгалә нәрсә әйтә - Корьәнгә таянабыз, аннан инде пәйгамбәребез хәдисләре белән баетабыз. Көндәлектә, тормышта булган гореф-гадәтләр дә чагылыш таба. Язылган вәгазьне халыкка чыгып сөйлибез, китап, матбугат аша ирештерәбез. Әйткән сүзләребез, вәгазьләребез халыкка киләчәктә дә хезмәт итәргә, динебезне аңлатырга бер юл булырга тиеш бит, шуның өчен аның, сез әйткәнчә, "ташка басылып" калуы кирәк тә инде.

**- Сез "Ислам нуры" газетасына аның беренче адымнарыннан ук хәерһаклы булган кеше. Бүген безнең укучыларыбызның күпчелеге - чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез. Моның сере, сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз?**

- "Ислам нуры" - дин ирегә килгәннән соң чыга башлаган газеталарның берсе. 25 ел элек дини китаплар да, газеталар да юк иде, без аларга мохтаҗ идек. "Ислам нуры" шул мәлдә - халыкның чын мәгънәсендә гыйлемгә сусаган, дингә омтылган вакытында чыкты. Дини дәреслекләр юк, газета битләрендә чыккан вәгазьләрне зарыгып көтеп алалар иде, авылларда бик күп имамнар шушы вәгазьләрне сөйләделәр, һәр җомгада кулландылар. Хәтерлим әле, төрле чит төбәкләрдән рәхмәт әйтеп язган бик күп хатлар килә иде. Чөнки газетаны үзебезнең республика халкы гына түгел, башка төбәкләр дә элек-электән күпләп яздыра иде. Тора-бара, укучылардан сораулар килә башлагач, сорау-җавап рубрикасын да керттек, шул рәвешле газетаның дәрәҗәсе тагын да үсте, күтәрелде. Кешеләр үзләрен кызыксындырган сорауларга шәригать белгеченнән җавап алалар иде. "Менә шундый сораулар килгән", - дип, аларны вәгазьләрдә дә ирештерәләр иде. Газета ул чорда да, хәзер дә халыкка хезмәт итә торган бер басма ул.

Бездә, Аллага шөкер, бүген китапларга кытлык шактый кимеде. "Хозур" нәшрияты, "Иман" нәшрияты бар, китаплар чыгып тора. Шулай да читтә яшәүче милләттәшләребезгә бездә чыккан китаплар турыдан-туры барып җитмәскә дә мөмкин, кемдер алып кайтса яки җибәрсә генә инде. Ә газетаны өйгә яздырып алырга була, ул айга ике тапкыр килә. Тагын шунысы да бар: читтә, башка халыклар арасында яшәгән татарлар үзенең теле өчен дә, дине өчен дә күбрәк кайгырта, күбрәк белергә тырыша. Без исә монда проблемаларны күрмәмешкә салышабыз... Югыйсә, татар телендә чыга торган газетада балалар өчен дә рубрика бар, төрле теманы яктырткан эчтәлекле язмалар да. Татар халкы - укый торган халык дибез, шул биеклектә калсын иде ул. Үз телендә укудан ерагаю - милләтнең теленнән ерагаюына китерә торган әйбер.

**- Сүзегезне дәвам итсәм... Бүген, чыннан да, дини әдәбият бик күп. Тик кайчагында, бер үк сорауга аларның төрлесендә төрлечә җавапка очрагач, аптырап һәм икеләнеп калырга мәҗбүр буласың: кайсы дөрес тә, кайсы хаталы? Гыйлемсез кеше үзен чытырманлык уртасында калгандай хис итәргә мөмкин...**

- Нинди генә сорау булмасын, без бу мәсьәләдә иң беренче итеп Корьәнгә карарга тиешбез: бу сорау буенча Аллаһы Тәгалә нәрсә әйткән - шуның белән җавап бирергә тиешбез. Икенчесе: әгәр җавапны Корьәндә тапмасак, пәйгамбәребез хәдисләренә кайтабыз. Аннан - сәхәбәләрнең сүзләренә, аннан - табигыйннәрнең, аннан - галимнәрнең сүзләренә кайтабыз. Шул рәвешле сорауга эзлекле җавап бирергә тиешбез. Ә кайбер җавап бирүчеләр үз фикерләрен куялар һәм ул фикер халыкка бер фәтва булып яңгырый. Тик синең фикерең халыкны буташтыруга да китерергә мөмкин бит әле. Бу әйбергә хәзер әкренләп киртә куела бара. Китапларны Диния нәзарәтендәге Голәмәләр шурасы тикшереп, раслап, чыгарырга рөхсәт биргәч кенә бастыру күздә тотыла. Календарьлар буенча да сораулар туып тора, аларны күптөрле җирләрдә чыгарлар. Халыкны бутамас өчен, җавап бирүчеләрнең, үз фикерләрен куймыйча, галимнәр фикеренә таянулары мөһим. Үзебезнең җирлектә булган галимнәр фикеренә мөрәҗәгать итәргә тиешбез. Бүгенге көндә мондый мәсьәләләргә аныклык кертә башлады, Диния нәзарәтендә дә сорауларга җавап бирү өчен махсус бүлек бар.

**- Сүз соңында "Ислам нуры"на янә әйләнеп кайтсак... Үзегезне гап-гади бер укучы дип хис итсәгез, газетада нинди теманың даими чагылып баруын хуплар идегез?**

- Газета битләрендә вәгазьләрнең булуы матур күренеш, ул дәвам итсен. Иң мөһиме - алар халыкка аңлаешлы, гади телдә язылсын иде, галимнәр өчен гыйльми рәвештә түгел. Халык аңласын, кабул итсен. Хәерле, матур эшләрне яктырту кирәк дип саныйм, кешегә үрнәк булырлык, аны канатландырып җибәрерлек... "Исламга хикмәт белән, яхшы сүзләр белән чакырыгыз", - ди бит Аллаһы Тәгалә. Хәтта бәхәсләшкәндә дә иң матур сүзләр белән бәхәсләшегез, ди. Шулай булгач, әйткәнемчә, яхшылыкны, матурлыкны күбрәк яктыртырга кирәк.

**Әңгәмәдәш - Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА.**

# Кылган хаҗым – Аллаһ биргән таҗым

Кем әйтә тормышта могҗиза булмый дип?! Мин иллегә җиткәндә, могҗизага ышана башладым...

1993 елның 25 маена каршы төндә, бер укытучыбызның гаиләсендә янгын чыгып, үзе, ире белән 10 айлык уллары бик каты пештеләр. Үзенең исән калуы да шикле иде. Мәктәп директоры булып эшләгән вакытым. Әлеге бәхетсезлеккә тарыган укытучы бер мәктәптә, миннән бер сыйныф кына түбән укыды. Әлеге хәсрәтне «ил белән күтәрергә» кирәк иде. Дәвалану өчен шактый күләмдә акча таләп ителде. Үземнең кул астында эшләүче укытучы буларак, ярдәм сорап, райондагы барлык авыл һәм шәһәр мәгариф оешмаларына мөрәҗәгать итеп, шактый гына ярдәм итә алдык. Аллаһының рәхмәте белән, терелергә өмет бик аз дигән укытучыбыз, бүгенге көндә исән-имин. Ире белән уллары да савыкты. Ә шул вакытта күргән бер төшем әле дә онытылмый. Имеш, миңа хаҗга барырга дип, кешеләр акча җыялар икән. Ул да булмый, мин, аякны бөкләп, ап-ак колонналы зур гына ак бинада утырам. Шунда минем алдыма китап китереп куйдылар. Ул чакта мин, 25 яше дә тулмаган егет, әллә ни уйламадым да. Шулай да, халыкта «Хаҗ сәвабы бирсен Ходай» дигән теләк бар бит. Мин дә, үземчә, «шушы ярдәмнәрем өчен шундый төш кергәндер» дип тынычланып калдым. Һәм менә, Аллаһының рәхмәте белән, шул вакыйгадан соң нәкъ 25 ел үткәч, Татарстан Диния нәзарәтеннән шалтыраттылар: «Сез хаҗга барасыз. Чит илгә чыгу өчен паспортыгыз бармы? Булмаса, тиз арада эшләтегез», – диделәр. Мин аптырап калдым. «Гафу итегез, Сез мине кем беләндер бутадыгыз бугай», – дидем мин, телемне көчкә әйләндереп. « Юк, юк, бутамадык. Сез бит Буадан, абый, әйме?» – диде трубканың теге башындагы мөлаем тавыш. «Әйтәм бит, сез ялгыштыгыз. Әлмәттән мин», – дидем, бераз тынычланып. Тик шалтыратучы егет бик үҗәт булып чыкты. «Абый, фамилиягезне әйтегез әле. Хәзер исемлекне барлыйм мин», – диде. Мин фамилиямне әйттем. «Бар, бар сезнең фамилия, абый. Сез президент программасы нигезендә хаҗга барасыз. Без сезгә әле тагын шалтыратырбыз. Әссәләмүгаләйкум», – дип саубуллашып, егет телефонын куйды. Мин ни шатланырга, ни борчылырга белмәдем, аптырап калдым. Чөнки бу көтелмәгән, хыялланырга да батырчылык итми торган нәрсә иде.

*(Дәвамы бар).*

**Рәфкать ШАҺИЕВ,**
**Әлмәт шәһәре.**

# Намаз вакытлары

| Милади март | Көн исеме | Рәҗәб-Шәгъбан | Иртәнге намаз | | | | | | Кояш чыга | | | Зәвәл | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ястү | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Таң беленә | | | Мәчетләрдә укыла | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Як | 6 | 06.06 | 04:18 | 04:31 | 06.18 | 04:50 | 05:03 | 08.08 | 06:20 | 06:33 | 13.27 | 11:42 | 11:55 | 13.38 | 12.00 | 12.00 | 16.07 | 15:08 | 15:21 | 19.11 | 17:05 | 17:18 | 20.23 | 18:46 | 19:00 |
| 2 | Дш | 7 | 06.04 | 04:15 | 04:28 | 06.16 | 04:48 | 05:01 | 08.06 | 06:18 | 06:31 | 13.27 | 11:42 | 11:55 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 16.08 | 15:10 | 15:23 | 19.13 | 17:07 | 17:20 | 20.25 | 18:48 | 19:02 |
| 3 | Сш | 8 | 06.01 | 04:12 | 04:25 | 06.13 | 04:45 | 04:58 | 08.03 | 06:15 | 06:28 | 13.27 | 11:42 | 11:55 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 16.10 | 15:11 | 15:24 | 19.15 | 17:09 | 17:22 | 20.27 | 18:51 | 19:04 |
| 4 | Чш | 9 | 05.59 | 04:10 | 04:23 | 06.11 | 04:43 | 04:56 | 08.01 | 06:13 | 06:26 | 13.27 | 11:42 | 11:55 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 16.11 | 15:13 | 15:26 | 19.17 | 17:11 | 17:25 | 20.29 | 18:53 | 19:06 |
| 5 | Пҗ | 10 | 05.56 | 04:07 | 04:20 | 06.08 | 04:40 | 04:53 | 07.58 | 06:10 | 06:23 | 13.27 | 11:41 | 11:54 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 16.13 | 15:15 | 15:28 | 19.19 | 17:14 | 17:27 | 20.32 | 18:55 | 19:08 |
| 6 | Җм | 11 | 05.54 | 04:05 | 04:18 | 06.06 | 04:38 | 04:51 | 07.55 | 06:08 | 06:21 | 13.26 | 11:41 | 11:54 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 16.14 | 15:17 | 15:30 | 19.21 | 17:16 | 17:29 | 20.34 | 18:57 | 19:11 |
| 7 | Шм | 12 | 05.51 | 04:02 | 04:15 | 06.03 | 04:35 | 04:48 | 07.53 | 06:05 | 06:18 | 13.26 | 11:41 | 11:54 | 13.36 | 12.00 | 12.00 | 16.16 | 15:19 | 15:32 | 19.23 | 17:18 | 17:31 | 20.36 | 18:59 | 19:13 |
| 8 | Як | 13 | 05.49 | 03:59 | 04:12 | 06.00 | 04:32 | 04:46 | 07.50 | 06:02 | 06:16 | 13.26 | 11:41 | 11:54 | 13.36 | 12.00 | 12.00 | 16.17 | 15:20 | 15:33 | 19.26 | 17:20 | 17:33 | 20.38 | 19:01 | 19:15 |
| 9 | Дш | 14 | 05.46 | 03:57 | 04:10 | 05.58 | 04:30 | 04:43 | 07.48 | 06:00 | 06:13 | 13.26 | 11:40 | 11:53 | 13.36 | 12.00 | 12.00 | 16.19 | 15:22 | 15:35 | 19.28 | 17:22 | 17:35 | 20.40 | 19:03 | 19:17 |
| 10 | Сш | 15 | 05.44 | 03:54 | 04:07 | 05.55 | 04:27 | 04:40 | 07.45 | 05:57 | 06:10 | 13.25 | 11:40 | 11:53 | 13.35 | 12.00 | 12.00 | 16.20 | 15:24 | 15:37 | 19.30 | 17:24 | 17:37 | 20.42 | 19:06 | 19:19 |
| 11 | Чш | 16 | 05.41 | 03:51 | 04:04 | 05.52 | 04:25 | 04:38 | 07.42 | 05:55 | 06:08 | 13.25 | 11:40 | 11:53 | 13.35 | 12.00 | 12.00 | 16.21 | 15:26 | 15:39 | 19.32 | 17:26 | 17:39 | 20.45 | 19:08 | 19:21 |
| 12 | Пҗ | 17 | 05.38 | 03:48 | 04:01 | 05.49 | 04:22 | 04:35 | 07.40 | 05:52 | 06:05 | 13.25 | 11:40 | 11:53 | 13.35 | 12.00 | 12.00 | 16.23 | 15:27 | 15:40 | 19.34 | 17:28 | 17:41 | 20.47 | 19:10 | 19:24 |
| 13 | Җм | 18 | 05.35 | 03:45 | 03:58 | 05.46 | 04:20 | 04:33 | 07.37 | 05:50 | 06:03 | 13.25 | 11:39 | 11:52 | 13.35 | 12.00 | 12.00 | 16.24 | 15:29 | 15:42 | 19.36 | 17:30 | 17:43 | 20.49 | 19:12 | 19:26 |
| 14 | Шм | 19 | 05.33 | 03:42 | 03:55 | 05.44 | 04:17 | 04:30 | 07.35 | 05:47 | 06:00 | 13.23 | 11:39 | 11:52 | 13.34 | 12.00 | 12.00 | 16.26 | 15:31 | 15:44 | 19.38 | 17:32 | 17:45 | 20.51 | 19:14 | 19:28 |
| 15 | Як | 20 | 05.30 | 03:40 | 03:53 | 05.41 | 04:14 | 04:28 | 07.32 | 05:44 | 05:58 | 13.23 | 11:39 | 11:52 | 13.34 | 12.00 | 12.00 | 16.27 | 15:32 | 15:45 | 19.40 | 17:34 | 17:47 | 20.53 | 19:17 | 19:30 |
| 16 | Дш | 21 | 05.27 | 03:37 | 03:50 | 05.38 | 04:12 | 04:25 | 07.29 | 05:42 | 05:55 | 13.23 | 11:38 | 11:52 | 13.34 | 12.00 | 12.00 | 16.28 | 15:34 | 15:47 | 19.42 | 17:36 | 17:49 | 20.56 | 19:19 | 19:33 |
| 17 | Сш | 22 | 05.24 | 03:34 | 03:47 | 05.35 | 04:09 | 04:22 | 07.27 | 05:39 | 05:52 | 13.23 | 11:38 | 11:51 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 16.30 | 15:36 | 15:49 | 19.44 | 17:38 | 17:51 | 20.58 | 19:21 | 19:35 |
| 18 | Чш | 23 | 05.21 | 03:31 | 03:44 | 05.32 | 04:07 | 04:20 | 07.24 | 05:37 | 05:50 | 13.23 | 11:38 | 11:51 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 16.31 | 15:37 | 15:50 | 19.46 | 17:40 | 17:53 | 21.00 | 19:23 | 19:37 |
| 19 | Пҗ | 24 | 05.19 | 03:28 | 03:41 | 05.29 | 04:04 | 04:17 | 07.21 | 05:34 | 05:47 | 13.23 | 11:38 | 11:51 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 16.32 | 15:39 | 15:52 | 19.49 | 17:42 | 17:55 | 21.03 | 19:26 | 19:40 |
| 20 | Җм | 25 | 05.16 | 03:25 | 03:38 | 05.26 | 04:01 | 04:14 | 07.19 | 05:31 | 05:44 | 13.23 | 11:37 | 11:50 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 16.34 | 15:41 | 15:54 | 19.51 | 17:44 | 17:57 | 21.05 | 19:28 | 19:42 |
| 21 | Шм | 26 | 05.13 | 03:22 | 03:34 | 05.23 | 03:59 | 04:12 | 07.16 | 05:29 | 05:42 | 13.23 | 11:37 | 11:50 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 16.35 | 15:42 | 15:55 | 19.53 | 17:46 | 17:59 | 21.07 | 19:30 | 19:44 |
| 22 | Як | 27 | 05.10 | 03:18 | 03:31 | 05.20 | 03:56 | 04:09 | 07.13 | 05:26 | 05:39 | 13.22 | 11:37 | 11:50 | 13.32 | 12.00 | 12.00 | 16.36 | 15:44 | 15:57 | 19.55 | 17:48 | 18:02 | 21.10 | 19:33 | 19:47 |
| 23 | Дш | 28 | 05.07 | 03:15 | 03:28 | 05.17 | 03:54 | 04:07 | 07.11 | 05:24 | 05:37 | 13.22 | 11:36 | 11:49 | 13.32 | 12.00 | 12.00 | 16.38 | 15:45 | 15:58 | 19.57 | 17:50 | 18:04 | 21.12 | 19:35 | 19:49 |
| 24 | Сш | 29 | 05.04 | 03:12 | 03:25 | 05.14 | 03:51 | 04:04 | 07.08 | 05:21 | 05:34 | 13.22 | 11:36 | 11:49 | 13.32 | 12.00 | 12.00 | 16.39 | 15:47 | 16:00 | 19.59 | 17:52 | 18:06 | 21.14 | 19:38 | 19:51 |
| 25 | Чш | 1 | 05.01 | 03:09 | 03:22 | 05.11 | 03:48 | 04:01 | 07.05 | 05:18 | 05:31 | 13.21 | 11:36 | 11:49 | 13.31 | 12.00 | 12.00 | 16.40 | 15:48 | 16:02 | 20.01 | 17:54 | 18:08 | 21.17 | 19:40 | 19:54 |
| 26 | Пҗ | 2 | 04.58 | 03:06 | 03:19 | 05.08 | 03:46 | 03:59 | 07.03 | 05:16 | 05:29 | 13.21 | 11:35 | 11:49 | 13.31 | 12.00 | 12.00 | 16.41 | 15:50 | 16:03 | 20.03 | 17:56 | 18:10 | 21.19 | 19:42 | 19:56 |
| 27 | Җм | 3 | 04.55 | 03:02 | 03:15 | 06.04 | 03:43 | 03:56 | 07.00 | 05:13 | 05:26 | 13.21 | 11:35 | 11:48 | 13.31 | 12.00 | 12.00 | 16.43 | 15:52 | 16:05 | 20.05 | 17:58 | 18:12 | 21.22 | 19:45 | 19:59 |
| 28 | Шм | 4 | 04.51 | 02:59 | 03:12 | 05.01 | 03:40 | 03:54 | 06.57 | 05:10 | 05:24 | 13.20 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.44 | 15:53 | 16:06 | 20.07 | 18:01 | 18:14 | 21.24 | 19:47 | 20:01 |
| 29 | Як | 5 | 04.48 | 02:56 | 03:09 | 04.58 | 03:38 | 03:51 | 06.55 | 05:08 | 05:21 | 13.20 | 11:35 | 11:48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.45 | 15:55 | 16:08 | 20.09 | 18:03 | 18:16 | 21.27 | 19:50 | 20:04 |
| 30 | Дш | 6 | 04.45 | 02:52 | 03:05 | 04.55 | 03:35 | 03:48 | 06.52 | 05:05 | 05:18 | 13.20 | 11:34 | 11:47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.46 | 15:56 | 16:09 | 20.12 | 18:05 | 18:18 | 21.29 | 19:52 | 20:06 |
| 31 | Сш | 7 | 04.42 | 02:49 | 03:02 | 04.52 | 03:33 | 03:46 | 06.49 | 05:03 | 05:16 | 13.20 | 11:34 | 11:47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.47 | 15:58 | 16:11 | 20.14 | 18:07 | 18:20 | 21.32 | 19:55 | 20:08 |

## Исем туе



Бүген бездә оҗмах сые,
Курчагымның исем туе!
Кунак җыйдык күп итеп.
Аякка кидем читек,
Калфак салдым башыма,
Әбием дә каршымда.
Курчагымны матурлап,
Төреп ап-ак җаймәгә,
Яткырдым да мендәргә,
Бабаема ым кактым.

*Балалар өчен*

Бабам ак түбәтәен,
Тагын бер кат төзәтеп,
Барыгыз да әзерме? –
Дигән сыман, кузәтеп,
Азан башлады көйләп,
Курчагымның колагына
Изге аятен сөйләп:
"Атың Гөлзәйнәп булсын,
Сине уйнаткан баланың
Күңеленә нур тулсын!
Яратсын Туган җирен,
Туган телен, әнисен,
Әби-бабай, әтисен!
Алар аша нәселгә
Иманлы җаннар иңсен!" –
Диде кулын күтәреп.
Амин! – дидек һәммәбез,
Җөпләп бабамның сүзен.
Дога балкыткан иде
Һәммәбезнең дә йөзен!

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА.**

## Саулыгым – байлыгым



Мүк җиләгендә аскорбин кислотасын үзләштерүгә ярдәм итүче PP витамины бар. Ул иммунитетны ныгыта. Мүк җиләгендә С һәм В витамины да күп. Мүк җиләгеннән ясалган морс һәм компотны салкын тигән вакытта эчәргә кирәк. Ул температураны төшерә, сусауны баса, организмнан токсиннарны чыгара. Бал белән буталган мүк җиләге согы ангинага каршы көрәшә, инфекцияләрдән саклый. Әлеге җиләк йөрәк һәм кан тамырлары авыруларыннан җәфаланучылар өчен дә файдалы, чөнки ул кандагы начар холестеринның күләмен киметә, гипертония белән көрәшә. Кан басымы аның сидек кудыру үзлегенә ия булуы аркасында төшә. Шундый башка чаралардан аермалы буларак, мүк җиләге организмнан кан тамырларын ныгытучы калийны юып чыгармый.

Мүк җиләге йөрәк авырулары вакытында чикләнергә тиешле тозны да алыштыра ала. Ризыгыгызга тоз урынына мүк җиләге согы кушсагыз, ул тәмен тоелмас. Башы авыртып интегүчеләргә көненә бер тапкыр бал белән мүк җиләге катнашмасын ашарга киңәш ителә. Моның өчен алары бертигез күләмдә алына, мүк җиләге иттарткыч аша чыгарыла.

(Фотолар интернеттан алынды)

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселман-нары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!
Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.
Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *
Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**
**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**12 февраль 16 сәг.**
**фактта 12 февраль 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**